ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2019 г.Мензелинск № 340

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль район территориясендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туганда җәмәгать тәртибен саклау турындагы Нигезләмәне раслау турында

1994 елның 21 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында”гы №68-ФЗ, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү буенча бердәм дәүләт системасы турында”гы №794 карары, Татарстан Республикасының 2004 елның 8 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турына”гы №62-ЗРТ, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елныц 3 декабрендәге “Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм төбәкара характердагы гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы №1075 карары нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау максатларында, Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район территориясендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туганда җәмәгать тәртибен саклау турындагы беркетелгән Нигезләмәне расларга.
2. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе, Минзәлә муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе Р.Ф.Ягафаровка йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитеты карары нигезендә
расланган

дата 27.03.2019 № 340

# Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район территориясендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туганда җәмәгать тәртибен саклау турындагы Нигезләмә

1. Минзәлә муниципаль район территориясендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туганда җәмәгать тәртибен саклау турындагы Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 1994 елның 21 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында”гы №68-ФЗ, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү буенча бердәм дәүләт системасы турында”гы №794 карары, Татарстан Республикасының 2004 елның 8 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турына”гы №62-ЗРТ, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 3 декабрендәге “Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм төбәкара характердагы гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы №1075 карары нигезендә эшләнгән.
2. Гамәлдәге нигезләмә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район территориясендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туганда җәмәгать тәртибен саклауга юнәлтелгән чараларны оештыруны билгели.
3. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносының функцияләшүе кысаларында башкарыла.
4. Җәмәгать тәртибен саклаганда төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

массакүләм мәгълүмат чаралары аша, шулай ук хәбәр итүнең мобиль чараларын кулланып, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу турында яки килеп чыгу куркынычы турында халыкка хәбәр җиткерү;

гадәттән тыш хәлләр зонасында контроль-үткәрү режимын оештыру;

гадәттән тыш хәлләр зонасында барлык төр транспорт чараларының хәрәкәтен җайга салуны оештыру;

потенциаль куркыныч тудыручы объектларны, тереклекне тәэмин итүче объектларны, зыян күрүчеләрнең шәхси мөлкәтен һәм матди байлыкларын саклау,

гадәттән тыш хәлләр зонасында хокук бозучыларны кисәтү һәм булдырмау;

авария-коткару эшләрендә катнашмаучы затларның үтеп керүен булдырмау өчен гадәттән тыш хәлләр зонасын блокировкалауны (изоляцияләү, чогап алу) башкару;

эвакуация чараларын уздырганда җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү;

паника, ялган һәм провокацияле хәбәрләр таралуны, шулай ук законга каршы гамәлләрне кисәтү;

югалган кешеләрне эзләү;

мәетләрне идентификацияләү;

җәмәгать тәртибен саклау өчен җәлеп ителгән көч һәм чараларның составын билгеләү һәм әзерләү, гамәлләрне планлаштыру.

5. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү өчен

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүнең бердәм дәүләт системасы турында”гы карары белән билгеләнгән тәртиптә көч һәм чаралар җәлеп ителә.

6. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү өчен көч һәм чараларны җәлеп итү Минзәлә муниципаль районында

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Комиссия карары нигезендә башкарыла.

7. Минзәлә муниципаль район территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауга юнәлтелгән чараларны оештыруда катнашучы Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм лквидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносының көч һәм чараларын координацияләү һәм идарә итүне тәэмин итү максатларында, тиешле оператив штаб булдырыла, ул шул исәптән гадәттән тыш хәл зонасында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча карарны булдыра.

8. Минзәлә муниципаль район территориясендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауга һәм аларның үзара бәйләнешен оештыруга юнәлтелгән чараларны оештыруда катнашучы көч һәм чаралар белән гомуми җитәкчелек итүне Минзәлә муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү Комиссиясе башкара.

9. Җәмәгать тәртибен саклауга җәлеп ителүче көч һәм чаралар килеп җиткәнче җәмәгать тәртибен саклау гадәттән тыш хәлләр зонасына беренче булып килгән авария-коткару хезмәте (авария-коткару формированиесе) җитәкчесе тарафыннан оештырыла.

10. Әгәр Россия Федерациясе законнары белән башкача каралмаган булса, гадәттән тыш хәлләр зонасында булган барлык гражданнар һәм оешмалар өчен гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү буенча эшләр җитәкчесе карары мәҗбүри булып тора.

11. Минзәлә муниципаль район территориясендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауга юнәлтелгән чаралар уздырганда, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре территораиль органнарыныц көч һәм чаралары федераль законнарда билгеләнгән бурычлар һәм вәкаләтләр нигезендә кулланыла.